**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.01.2021 ел № 6

Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карарына (2018 елның 03 маендагы 372 номерлы, 2018 елның 27 декабрендәге 1003 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (19 нчы кушымта):

2.4 пунктта «14 көн» сүзләрен «10 көн» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктындагы 1 пунктчасының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"-63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша uslugi/tatatrstan.ru электрон формада, квалификацияле электрон имза белән имзаланган (таныкланган) (гариза бирүче исеменнән эш итүче затлардан тыш)»;

2.5 нче пунктның 2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) мөрәҗәгать итүченең шәхесен һәм аның ЕСИАдан алынган реквизитларын стандарт учет язмасыннан (электрон рәвеш тутырылганда) түбәнрәк раслаучы документ;

2.5 пунктның 3 нче подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ яки аның скан-күчермәсе (электрон формада)

2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) Документларны тиешле булмаган органга тапшыру; гариза һәм документлар (документлар күчермәләре), 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләренә туры китереп, гади электрон имза белән кул куелмаган (расланмаган) документлар (документлар күчермәләре))»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча беренче урынбасары А.М. Шәрәфиевка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин